# КАРАР

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлеге Мордва Каратай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2019 елның 4 декабре                                                                 1 номерлы

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 4 декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

«2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге территориясе, Мордва Каратай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм 1 төркем инвалидлардан тыш) һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 50 кеше кертелгән, җыенда 27 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 27 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельск авыл җирлеге составына керүче Мордва Каратай авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге территориясе, Мордва Каратай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә (Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм 1 төркем инвалидлардан тыш) һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам һәм урамара юлларны төзекләндерү һәм карап тоту.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Мордва Каратай авылы, Центральная урамы, 7;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Кама<br>Тамагы муниципаль районы<br>Кирельск авыл җирлеге<br>башлыгы,<br>Халык җыенында рәислек итүче Ф.Я.Зиннәтуллин